КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 август г.Казань № 662

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы йөзендә «Университет Иннополис» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына кертү турында» 2018 ел, 26 июнь, 518 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы йөзендә «Университет Иннополис» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына кертү турында» 2018 ел, 26 июнь, 518 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы йөзендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин